| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ШУГУРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ШӨГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 2023елның 26 октябре | № 164 |

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 19 номерлы карары белән расланган «Агачларны, куакларны кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең яңа редакциядә административ регламентын раслау турында» карарына үзгәреш кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 19 номерлы карары белән расланган «Агачларны, куакларны кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында яңа редакциядә» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 августындагы 175 номерлы номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 8 августындагы 87 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021елның 3 августындагы 19 номерлы «Агачларны, куакларны кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең яңа редакциядә административ регламентын раслау турында» карарын һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 19 номерлы карары белән расланган Агачларны, куакларны кисүгә, кронацияләүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17 йорт административ бина, Киров ур., 23 йорт, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, Ленин урамы, 32 йорт, Шөгер авылы мәдәният йорты, Ленин урамы, 35 йорт, Шөгер участоок хастаханәсе, Горький урамы, 4 йорт, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Н.Гафиятуллин